ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

Постановление **Карар**

№ 337 от «23» 09 2020 г.

Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 19 маендагы «Аренда түләүләрен түләүдән азат итү өлешендә кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм чаралары турында» гы 187 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 6 августындагы «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 22 апрелендәге 821-р номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү турында» 1497-р номерлы боерыгы һәм Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрының 2020 елның 19 августындагы «Арендаторларга ярдәм чаралары күрсәтү буенча норматив актларга үзгәрешләр кертү турында» №1-31/10318 нче боерыгы нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 19 маендагы «Аренда түләүләрен түләүдән азат итү өлешендә кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм чаралары турында» гы 187 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта:

“а” пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

а) кече һәм урта эшкуарлык субъектларының бердәм реестрына кертелгән кече һәм урта эшкуарлык субъектлары арендаторлары, иҗтимагый файдалы хезмәт күрсәтүләрне башкаручы коммерциячел булмаган оешмалар реестрына кертелгән иҗтимагый юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар-башкаручылар реестрына кертелгән социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар-башкаручылар мөрәҗәгать иткән көннән алып җиде эш көне эчендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының дәүләт казнасын төзи торган дәүләт мөлкәтен (шул исәптән җир кишәрлекләрен) арендалау шартнамәләре буенча 2020 елның 1 апреленнән 2020 елның 1 октябренә кадәр түбәндәге шартларда аренда түләүләрен кичектерүне күздә тота торган өстәмә килешүләр төзү:

аренда түләве буенча бурыч 2021 елның 1 гыйнварыннан башлап, ләкин 2023 елның 1 гыйнварыннан да соңга калмыйча, айга бер тапкырдан да арттырмыйча,

0000010631

этаплап, аренда шартнамәсе буенча айлык аренда түләве күләменнән артмый торган тигез түләүләр белән арендага алучылар тәкъдим иткән срокта түләнергә тиеш;

кичектереп торуга бәйле рәвештә штрафлар, чит акчалардан файдаланган өчен процентлар яисә арендатор тарафыннан аренда түләвен кертү тәртибен һәм срокларын үтәмәүгә бәйле рәвештә жаваплылыкның башка чаралары кулланылмый (шул исәптән мондый чаралар аренда шартнамәсендә каралган очракларда);

кичектереп тору белән бәйле рәвештә арендатор тарафыннан түләнергә тиешле өстәмә түләүләр билгеләү рөхсәт ителми;

аренда шартнамәсе вакытыннан алда өзелгәндә аренда түләве буенча бурыч бер мәртәбә түләнә;»;

«б» пунктчасында «кече һәм урта эшкуарлык субъектлары» сүзләреннән соң «социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмалар» сүзләрен өстәргә;

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Аренда түләүләрен түләүне кичектерү кече һәм урта эшкуарлык субъектларының бердәм реестрына кертелгән кече һәм урта эшкуарлык арендаторларына, коммерциячел булмаган оешмаларга - иҗтимагый файдалы хезмәт күрсәтүләрне башкаручы коммерциячел булмаган оешмалар реестрына кертелгән, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы территориясендә югары әзерлек яисә гадәттән тыш хәл режимын кертү датасына карата Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы дәүләт казнасын төзи торган дәүләт мөлкәтен (шул исәптән җир кишәрлекләрен) арендалау шартнамәләре буенча узган чорда аренда түләүләрен түләү буенча үтәлмәгән бурычы булмаган иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтне башкаручыларга бирелә дип билгеләргә. »

2^1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2^1. 2020 елның 1 апреленә кадәр төзелгән һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектларының бердәм реестрына кертелгән кече һәм урта эшкуарлык субъектлары буенча арендаторлар булган дәүләт мөлкәтен арендалау шартнамәләре буенча башкарма хакимият органнары, шулай ук алар карамагындагы дәүләт предприятиеләре һәм дәүләт учреждениеләренә, яисә Россия икътисады тармаклары исемлеге буенча бер яки берничә тармакта эшчәнлекне гамәлгә ашыручы коммерциячел булмаган оешма-башкаручылар реестрына кертелгән, яңа коронавирус инфекциясе таралу нәтиҗәсендә хәлнең начарлануы шартларында иң күп зыян күрүче булган социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешма-башкаручылар Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 3 апрелендәге «Яңа короновирус йогышы таралу нәтиҗәсендә хәл начараю шартларында иң күп зыян күргән Россия икътисады тармаклары исемлеген раслау турында» 434 номерлы карары белән расланган яңа короновирус инфекциясе таралу нәтиҗәсендә килеп туган хәлнең начараюы шартларында аеруча зыян күрүчеләр исемлегенә үзгәрешләр кертү хакында»гы карары, Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 19 маендагы ««Аренда түләүләрен түләүдән азат итү өлешендә кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм чаралары турында» гы 187 нче карары нигезендә 2020 елда каралган аренда түләвен түләүне кичектереп торуны тәэмин итәргә».

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз жаваплылыгымда калдырам.

Житәкче И.М. Дәржеманов